**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2160**
**29.04.2016**

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезнамәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115, 117 маддәләре, шәһәр Уставының 74 маддәсе, Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезнамәнең 17 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2016 елның 29 апрелендәге
2160 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе һәм шартлары турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезнамә нигезендә, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен (алга таба – муниципаль гарантияләр) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль гарантияләр, әлеге нигезнамә нигезендә Шәһәр Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карарында күрсәтелгән һәм бирелә торган гарантияләрнең гомуми суммасы чикләрендә Башкарма комитет тарафыннан бирелә.

3. Муниципаль гарантия түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкин:

1) принципалның бенефициар каршындагы йөкләмәсен (төп йөкләмәне) тиешенчә үтәвен;

2) коммерциячел характерда булмаган гарантия очрагы килеп туганда барлыкка килгән зыянны түләтүне

Муниципаль гарантия инде барлыкка килгән йөкләмәләрне дә, шулай ук киләчәктә барлыкка килергә мөмкин булган йөкләмәләрне дә тәэмин итү өчен бирелергә мөмкин.

4. Гарант муниципаль гарантия шартларын бенефициар ризалыгыннан башка үзгәртә алмый.

Муниципаль гарантия буенча гарантка карата бенефициарның таләп хокукы, гарантиядә башкача каралмаган булса, башка затка тапшырыла алмый.

Гарант муниципаль гарантияне гарантиядә күрсәтелгән нигезләр буенча гына кире алу хокукына ия.

5. Муниципаль гарантиянең язма рәвеше мәҗбүри булып тора.

Муниципаль гарантиянең язма рәвешен үтәмәү аның гамәлдә булмавына (бернигә яраксызлыгына) китерә.

6. Муниципаль гарантияләр гарантның принципал тәэмин иткән йөкләмәсе буенча субсидиар яисә хезмәттәш җаваплылыкны күз алдында тотарга мөмкин.

7. Муниципаль гарантиядә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

1) гарантның исеме һәм гарант исеменнән гарантия биргән органның исеме;

2) тәэмин итү өчен гарантия бирелә торган йөкләмә;

3) гарантия буенча гарант йөкләмәләре күләме һәм гарантияләрнең иң чик суммасы;

4) гарантия очрагын билгеләү;

5) принципал исеме;

6) гарантияне кире алып булмау яисә аны кире алу шартлары;

7) гарантия бирү өчен нигезләр;

8) гарантиянең үз көченә керүе (бирү датасы);

9) гарантиянең гамәлдә булу срогы;

10) гарантның гарантия буенча йөкләмәләрен үтәү тәртибе;

11) гарантияне үтәгәндә һәм (яки) принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен үтәгәндә гарантиянең иң чик суммасын киметү тәртибе һәм шартлары;

12) муниципаль гарантия буенча бенефициарга гарант тарафыннан түләнгән суммаларны каплау турында принципалга карата гарант таләбе хокукы булу яки булмау (принципалга карата гарантның регресс таләбе, регресс);

13) гарантның хокукый актлары, гарант исеменнән гарантия биргән орган актлары белән билгеләнгән бүтән гарантия шартлары, шулай ук мәгълүматлар.

8. Муниципаль гарантиянең үз көченә керүе календарь дата яисә киләчәктә булырга мөмкин вакыйга (шарт) башлану белән билгеләнә.

Муниципаль гарантиянең гамәлдә булу срогы гарантия шартлары белән билгеләнә.

9. Муниципаль гарантия буенча акчалата сумманы түләү турында бенефициар таләбе, гарантиядә күрсәтелгән документларны теркәп, гарантка язма рәвештә тапшырылырга тиеш.

10. Бенефициар таләбен алганнан соң гарант бу хакта принципалга хәбәр итәргә һәм шуңа караган барлык документлары белән таләп күчермәсен аңа тапшырырга тиеш.

Гарант, бенефициар таләбенең һәм аңа теркәлгән документларның гарантия шартларына туры килү-килмәвен билгеләү өчен, әлеге таләпне, аңа теркәлгән документларны гарантиядә билгеләнгән срокта карарга тиеш.

11. Бенефициар таләбе һәм гарант тарафыннан бенефициар таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту түбәндәге очракларда нигезсез дип танылa:

1) таләп гарантиядә билгеләнгән срок узганнан соң гына гарантка бирелсә;

2) таләп яисә аңа теркәлгән документлар гарантия шартларына туры килмәсә;

3) бенефициар принципал яисә өченче затлар тәкъдим иткән принципал йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне кабул итүдән баш тартса.

Гарант бенефициарның таләбен канәгатьләндерүдән баш тартуы хакында аңа хәбәр итәргә тиеш.

Гарант бенефициар таләбенә каршы чыгарга хокуклы, гарантия шартларында башкача каралмаган булса, бу каршылыкны принципал тәкъдим итәргә мөмкин. Гарант, хәтта принципал әлеге каршылыклардан баш тарткан яисә үз бурычын таныган очракта да, шушы каршылыкларга хокукын югалтмый.

Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта, гарант гарантия буенча йөкләмәне гарантиядә билгеләнгән срокта үтәргә тиеш.

12. Гарантның бенефициар каршындагы муниципаль гарантиядә каралган йөкләмәсе бенефициар таләбе куелган вакытта үтәлми калган һәм гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләре суммасын түләү белән чикләнә, әмма бу гарантия бирелгән суммадан артмаска тиеш.

13. Гарантның муниципаль гарантия буенча бенефициар каршындагы йөкләмәсе түбәндәге очракларда туктатыла:

1) гарант бенефициарга гарантиядә билгеләнгән сумманы түләсә;

2) бирелгән гарантиянең гарантиядә билгеләнгән срогы узса;

3) принципал яисә өченче затлар принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен тулы күләмдә үтәсә;

4) бенефициар гарантияне гарантка кире кайтару яисә гарант йөкләмәләреннән аны азат итү турында гариза язу юлы белән үз хокукларыннан баш тартса;

5) тәэмин итү өчен гарантия бирелгән принципал йөкләмәсе барлыкка килмәсә;

6) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

Гарантның гарантия буенча йөкләмәләре туктатылганнан соң бенефициарның гарантияне тотып торуы аның шушы гарантия буенча булган нинди дә булса хокукларын саклап калмый.

Гарантия туктатылу турында мәгълүмат алган гарант бу хакта принципалга хәбәр итәргә тиеш.

14. Әгәр гарантның муниципаль гарантияне үтәве гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китерсә яисә бенефициарның принципалга карата таләп хокуклары гарантка юл бирү рәвешендә булса, мондый гарантияләрне үтәү тиешле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында исәпкә алына.

Әгәр гарантның муниципаль гарантияне үтәве гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китермәсә һәм бенефициарның принципалга карата таләп хокуклары гарантка юл бирү рәвешендә булмаса, мондый гарантияләрне үтәү тиешле бюджет чыгымнары составында чагылдырылырга тиеш.

Гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү (өлешчә үтәү) йөзеннән түләнгән суммалар регрессы тәртибендә гарантка түләү исәбенә, шулай ук бенефициардан гарантка күчкән таләп итү хокукы булган йөкләмәләрне үтәү исәбенә гарант алган акчалар бюджет кредитларын кире кайтару буларак исәпкә алына.

## 2 бүлек. Муниципаль гарантия бирү тәртибе һәм шартлары

15. Муниципаль гарантияләрне бирү Шәһәр Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турындагы карары, Башкарма комитет карары, шулай ук муниципаль гарантия бирү турындагы килешү нигезендә түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

1) принципалның финанс хәлен анализлау;

2) принципалның, аның җаваплылыгын үз өстенә алучыларның (гарантларның) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлек каршында акча йөкләмәләре буенча, Россия Федерациясе бюджеты системасына мәҗбүри түләүләр буенча срогы чыккан бурычлары, шулай ук моңа кадәр Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе субъектына, муниципаль берәмлеккә бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләре булмау.

Коммерциячел булмаган характердагы гарантия очрагында барлыкка килгән зыянны каплау буенча йөкләмәләрне тәэмин итү өчен муниципаль гарантия, шулай ук принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукыннан башка муниципаль гарантия биргәндә, принципалның финанс хәленә анализ ясалмаска мөмкин. Күрсәтелгән гарантияләрне биргәндә, принципалның гарант каршындагы гарант тарафыннан принципалга карата регресс таләпләре күрсәтү сәбәпле барлыкка килергә мөмкин булган йөкләмәләрен үтәвен тәэмин итү таләп ителми.

16. Муниципаль гарантия бирү, шулай ук муниципаль гарантия бирү турында килешү төзү принципал һәм (яки) бенефициар тарафыннан Башкарма комитетка, яисә агентка түбәндәге документларны тапшырганнан соң гамәлгә ашырыла:

1) әлеге нигезнамәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча гариза;

2) салым органыннан Россия Федерациясе бюджеты системасына, салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмауны раслый торган белешмә.

17. Муниципаль гарантия бирү максатында, шулай ук аны биргәннән соң принципалның финанс хәленә анализ ясауны, әлеге нигезнамәнең 20 пункты нигезендә, ул яки агент билгеләгән тәртиптә Башкарма комитетның финанс идарәсе гамәлгә ашыра.

18. Муниципаль гарантияләрне бирү һәм үтәү, шул исәптән муниципаль гарантияләрне бирү һәм үтәү, күрсәтелгән затларның бурычларын түләтү сәбәпле принципалның финанс хәлен анализлау, принципал, аның җаваплылыгын үз өстенә алучылар (гарантлар) һәм башка затлар йөкләмәләренең аналитик исәбен алып бару максатында, Башкарма комитет законда билгеләнгән тәртиптә, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә торган агент хезмәтләреннән файдалану хокукына ия.

19. Башкарма комитет муниципаль гарантияләрне бирү турында, гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү (өлешчә үтәү) йөзеннән гарант тарафыннан түләнгән суммалар регрессы тәртибендә гарантка түләүбуенча принципалның ихтимал киләчәк йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү турында килешүләр төзи һәм муниципаль гарантияләр бирә.

Гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү (өлешчә үтәү) йөзеннән гарант тарафыннан түләнгән суммалар регрессы тәртибендә гарантка принципалның түләү тәртибе һәм вакытлары гарант белән принципал арасындагы килешү белән билгеләнә. Бу мәсьәләләр буенча яклар килешүе булмаганда, гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү гарант таләбендә күрсәтелгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

20. Гарантия бирү вакытына бенефициарны билгеләү мөмкин булмаган яисә бенефициар билгесез затлар даирәсеннән гыйбарәт булган йөкләмәләрне тәэмин итү өчен бирелә торган муниципаль гарантияне бирү Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

21. Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләрнең гомуми суммасы эчке муниципаль бурыч составына бурыч йөкләмәсе төре буларак кертелә.

22. Муниципаль гарантияне бирү һәм үтәү муниципаль бурыч кенәгәсендә чагылдырылырга тиеш.

23. Башкарма комитетның финанс идарәсе бирелгән муниципаль гарантияләрнең, принципалның гарантияләр белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең үтәлешен, шулай ук бирелгән гарантияләр буенча гарант түләүләрен исәпкә алып бара.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль
гарантияләрен бирү тәртибе һәм
шартлары турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

Форма
Башкарма комитет
Җитәкчесе
________________________

Муниципаль гарантия бирү турында
гариза

_______________________________________________________________________
(оешманың исеме, ИНН)
_______________________________________________________________________
(юридик адресы)
Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантиясен бирү мөмкинлеген карауны сорый.
Гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмә: ______________________________
Муниципаль йөкләмә белән тәэмин ителә торган йөкләмәнең күләме:
_______________________________________________________________________
(сумма цифрлар һәм сүз белән языла)
Йөкләмә кем каршында тәэмин ителә (оешманың исеме): _____________________
Гарантиянең гамәлдә булу срогы: ___________________________________________
(календарь көннәрдә)

Оешма җитәкчесе ______________/__________________________)
(имза) (Ф.И.А.и.)

М.У. «_______» ____________ ______ ел

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

Форма
Яр Чаллы шәһәренең
муниципаль гарантиясен бирү турында
килешү №____

Яр Чаллы шәһәре «____»__________ 20___ ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән «ТР Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба «Гарант» дип атала, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эш итүче ____________________________________________ Башкарма комитет Җитәкчесе _______________________________ йөзендә, алга таба «Бенефициар» дип атала, ________________________________ һәм ______________________ ____________ нигезендә эш итүче _______________________________ йөзендә, алга таба «Принципал» дип атала, алга таба «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Принципал тарафыннан, ___________________ (______________________) суммадагы кредитны, шул исәптән төп бурычны – ______________ (_____________) һәм кредиттан файдаланган өчен процентларны – _____________ (________________) сум күләмендә кире кайтару буенча Принципал һәм Бенефициар арасында төзелгән «___» _______ 20___ ел №___ Кредит килешүе (алга таба – Кредит килешүе) буенча йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, Гарант Бенефициарның язмача таләбе буенча әлеге Килешү һәм «____» ________ 20___ ел № ____ Муниципаль гарантия (алга таба – Гарантия) белән билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Россия Федерациясе валютасындагы акчалата сумманы түләүне үз өстенә ала.

1.2. Гарантның бенефициар каршындагы Гарантиядә каралган йөкләмәсе бенефициар таләбе куелган вакытта үтәлми калган һәм гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләре суммасын түләү белән чикләнә, әмма бу гарантия бирелгән суммадан артмаска тиеш.

1.3. Принципал Кредит килешүе шартлары нигезендә Бенефициарга мөнәсәбәтле Гарантия белән тәэмин ителгән акча йөкләмәләрен үтәгән саен, Гарантның Гарантия буенча йөкләмәсе тиешле суммага кими.

1.4. Гарант Принципалның штрафлар, комиссияләр, пенялар түләү турындагы йөкләмәләре үтәлешен гарантияләми.

1.5. Принципалга Гарантия Гарантның Принципалга карата регресс таләбе хокукыннан башка бирелә.

## 2. ГАРАНТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Гарант хокуклы:

2.1.1. Гарантияне Гарантиядә күрсәтелгән нигезләр буенча гына кире алырга;

2.1.2. Гарантиядә каралган очракларда, Бенефициарга Гарантия буенча акча суммасын түләү турындагы таләбен (алга таба – Бенефициар таләбе) канәгатьләндерүдән баш тартырга;

2.1.3. Бенефициар таләбенә каршы чыгарга, Гарантия шартларында башкача каралмаган булса, бу каршылыкны Принципал тәкъдим итәргә мөмкин. Гарант, хәтта Принципал әлеге каршылыклардан баш тарткан яисә үз бурычын таныган очракта да, шушы каршылыкларга хокукын югалтмый.

2.2. Гарант бурычлы:

2.2.1. Принципалга Бенефициар таләбен алу турында хәбәр итәргә һәм барлык документлар белән бергә таләп күчермәсен аңа тапшырырга;

2.2.2. таләпнең һәм аңа теркәлгән документларның Гарантия шартларына туры килүен билгеләү өчен, барлык теркәлгән документлар белән бергә Бенефициар таләбен Гарантиядә билгеләнгән срокта карап тикшерергә;

2.2.3. Бенефициарга аның таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту турында хәбәр итәргә;

2.2.4. Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта, Гарантия буенча йөкләмәләрне Гарантиядә билгеләнгән срокта үтәргә;

2.2.5. Принципалга Гарантияне туктату турында хәбәр итәргә.

## 3. ПРИНЦИПАЛНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

3.1. Моның белән Принципал әлеге Килешү буенча барлык йөкләмәләрне үтәү өчен барлык кирәкле вәкаләтләргә ия булуын раслый һәм Принципалга бернинди өстәмә рөхсәтләр һәм килешенүләр таләп ителми.

3.2. Принципал түбәндәге йөкләмәләрне ала:

3.2.1. Принципалның Кредит килешүе шартларын үтәү буенча Бенефициар каршындагы үз йөкләмәләрен үтәмәү яки әлеге Килешү шартларын бозуга китерергә мөмкин булган нинди дә булса хәл туу очраклары турында Гарантка хәбәр итәргә;

3.2.2. Гарантның соравы буенча Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, конфиденциаль буларак карала торган мәгълүматны бирергә;

3.2.3. Гарантка Бенефициар белән барлыкка килгән фикер каршылыклары турында хәбәр итәргә.

## 4. БЕНЕФИЦИАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Бенефициар бурычлы:

4.1.1. Гарантиядә күрсәтелгән документларны теркәп, таләпне язма рәвештә бирергә;

4.1.2. түбәндәге вакыйгалар барлыкка килгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмый, Гарантка язмә рәвештә хәбәр итәргә:

- акчаны исәптән чыгару турында Принципалның исәп-хисап счеты буенча өземтәләрне, кредитлар түләү турында Принципалның ссуда счетлары буенча, шулай ук Бенефициарның вәкаләтле затлары тарафыннан имзаланган һәм Бенефициар мөһере белән расланган процентлар түләү турында процентларны исәпләү счетлары буенча өземтәләрне, шулай ук Бенфициарга акча күчерү турында Принципалның Бенифициар билгесе куелган түләү кәгазьләре күчермәләрен теркәп, Принципал, өченче затлар тарафыннан Кредит килешүе буенча йөкләмәләрнең өлешчә яки тулысынча үтәлүе турында;

- Кредит килешүен өзү турында;

- Принципал тарафыннан Бенефициар каршындагы үз йөкләмәләренең кайсын да булса үтәмәү турында, шулай ук Принципал тарафыннан кредитор яки өченче затлар каршындагы үз йөкләмәләрен үтәмәүгә китерергә мөмкин булган барлык хәлләр турында, шул ук вакытта Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә кирәкле мәгълүмат алу өчен барлык чараларны күреп;

4.1.3. Кредит килешүенә нинди дә булса үзгәрешләр яки өстәмәләр кертүгә Гарантның язмача ризалыгын алырга һәм килешенергә.

4.2. Гарантия буенча Гарантка карата Бенефициарның таләп хокукы башка затка тапшырыла алмый.

## 5. ГАРАНТИЯ БУЕНЧА ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ ҮТӘҮ

5.1. Принципал тарафыннан Кредит килешүе буенча йөкләмәлрне үтәү срогы җиткәч, Бенефициар Гарантка таләпләр куйганчы, Принципалга карата тиешле түләүләр турында язмача таләп куярга тиеш. Әгәр Принципал 15 эш көне эчендә Бенефициар куйган таләп буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәсә, Бенефициар Гарантия буенча Гарант йөкләмәләрен үтәү турында язмача таләп белән Гарантка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5.2. Бенефициар таләбе Гарантка, түбәндәге документларны теркәп, язма рәвештә бирелергә тиеш:

5.2.1. хисап көненнән соң икенче көнгә ссуда счетлары һәм Принципал процентларын исәпләү счетлары буенча өземтә;

5.2.2. срогы чыккан түләнмәгән төп бурыч күләмен һәм түләнмәгән срогы чыккан процентлар күләмен раслый торган исәпләүләр;

5.2.3. Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында Принципалга мөрәҗәгате;

5.2.4. Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында мөрәҗәгатенә Принципалның җавабы (булган очракта).

Бенфициар таләбенә теркәлгән документлар Бенефициарның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган һәм Бенефициар мөһере белән расланган булырга тиеш.

5.3. Бенефициар таләбе Гарантка кергән дата таләп куелган дата булып санала.

5.4. Гарант Бенефициарның таләбен һәм аңа теркәлгән документларны, таләп куелган көннән соң 10 эш көне эчендә карап тикшерә.

5.5. Бенефициар таләбе һәм Гарант тарафыннан Бенефициар таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту түбәндәге очракларда нигезсез дип таныла:

5.5.1. таләп Гарантиядә билгеләнгән срок узганнан соң гына Гарантка бирелсә;

5.5.2. таләп яисә аңа теркәлгән документлар Гарантия шартларына туры килмәсә;

5.5.3. Бенефициар Принципал яисә өченче затлар тәкъдим иткән Принципал йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне кабул итүдән баш тартса.

5.6. Бенефициар таләбен нигезле дип тану кире кагылган очракта Гарант, таләп куелган көннән соң 10 көн эчендә, Бенефициарга әлеге таләпне канәгатьләндерүдән баш тарту турында нигезле хәбәр җибәрә.

5.7. Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта Гарант, Бенефициар таләбе нигезле дип танылган көннән соң 30 эш көне эчендә, Гарантия буенча йөкләмәне үти.

## 6. ГАРАНТИЯНЕ КИРЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

6.1. Гарантия Гарант тарафыннан түбәндәге очракларда кире алынырга мөмкин:

6.1.1. Кредит килешүенә Гарант белән килешенмәгән һәм җаваплылыкны арттыруга яки Гарант өчен башка тискәре нәтиҗәләргә китерә торган шартлар кертелгәндә, шул исәптән кредит һәм кредит буенча процент ставкасы күләме, Кредит килешүенең гамәлдә булу срогы үзгәргән очракта;

6.1.2.Кредит килешүен өзгәндә.

## 7. ГАРАНТИЯНЕҢ ГАМӘЛДӘГЕ ВАКЫТЫН ТУКТАТУ

7.1. Гарантның Гарантия буенча Бенефициар каршындагы йөкләмәләре түбәндәге очракларда туктатыла:

7.1.1. Гарант Гарантия белән билгеләнгән сумманы Бенефициарга түләгәндә;

7.1.2. Гарантиянең билгеләнгән бирелү срогы чыкканда;

7.1.3. Принципал яки өченче затлар тарафыннан Принципалның Гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләре тулы күләмдә үтәлгән очракта;

7.1.4. Бенефициар Гарантка кире кайтару юлы яки Гарантны аның йөкләмәләреннән азат итү турында язмача гаризасы белән Гарантия буенча үз хокукларыннан баш тарту нәтиҗәсендә;

7.1.5. Принципалның тәэмин итү өчен Гарантия бирелгән йөкләмәсе барлыкка килмәсә.

## 8. ГАРАНТИЯНЕҢ ГАМӘЛДӘГЕ СРОГЫ

8.1. Гарантия «____» ___________ 20___ елдан үз көченә керә һәм «____» _________ 20___ елга кадәр гамәлдә була.

## 9. БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ

9.1. Әлеге Килешү һәм Гарантия белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр Россия Федерациясе законнары белән җайга салына.

9.2. Яклар арасында барлыкка килгән бәхәсләр сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

9.3. Бәхәсле мәсьәләләр җайга салынмаган очракта Яклар, бәхәсне хәл итү өчен, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә арбитраж судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## 10. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

10.1. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә төзелде.

10.2. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр язма рәвештә Яклар тарафыннан кертелә.

10.3. Әлеге Килешү Гарантиянең гамәлдә булу срогына төзелде.

10.4. Әлеге Килешүнең 6.1 һәм 7.1 пунктларында каралган нигезләр буенча Гарантия кире алынган яки аның гамәлдәге вакыты туктатылган очракта, Гарантия йөкләмәсе дә туктатыла.

## 11. ЯКЛАРНЫҢ ЮРИДИК АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| | | |
|---|---|---|
| «Гарант» | «Принципал» | «Бенефициар» |

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантияләрен бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

Форма

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль гарантиясе № _____

Яр Чаллы шәһәре «____»__________ 20___ ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән «ТР Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, алга таба «Гарант» дип атала, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «___»_________ 20___ ел №____ карары нигезендә эш итүче ____________________ ____________________________ йөкләмәләрнең үтәлеше өчен җавап бирүне үз өстенә ала, алга таба «Принципал» дип атала, Устав нигезендә эш итүче ___________________________ йөзендә, ____________________ каршында, алга таба «Бенефициар» дип атала, _________________________ йөзендә, түбәндәге шартларда:

1. Принципал тарафыннан, ________________ (___________________) суммадагы кредитны, шул исәптән төп бурычны – _______________ (_____________) һәм кредиттан файдаланган өчен процентларны – _____________ (________________) сум күләмендә кире кайтару буенча Принципал һәм Бенефициар арасында төзелгән бирү лимиты буенча кредит линиясе ачуга «____» _________ 20___ ел №___ Килешү (алга таба – Кредит килешүе) буенча йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, Гарант Бенефициарның язмача таләбе буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына ________________ (______________) күләмендә акчалата сумманы түләүне үз өстенә ала.

2. Бенефициарның әлеге Гарантия (алга таба – Гарантия) буенча акча суммасын түләү турындагы таләбе Гарантка, түбәндәге документларны теркәп, язма рәвештә бирелергә тиеш:

1) хисап көненнән соң икенче көнгә ссуда счетлары һәм Принципал процентларын исәпләү счетлары буенча өземтә;

2) срогы чыккан түләнмәгән төп бурыч күләмен һәм түләнмәгән срогы чыккан процентлар күләмен раслый торган исәпләүләр;

3) Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында Принципалга мөрәҗәгате;

4) Бенефициарның Кредит килешүе буенча йөкләмәләрне үтәү турында мөрәҗәгатенә Принципалның җавабы (булган очракта).

Бенфициар таләбенә теркәлгән документлар Бенефициарның вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган һәм Бенефициар мөһере белән расланган булырга тиеш.

3. Гарант Бенефициар таләбен һәм аңа теркәлгән документларны, таләп куелган көннән соң 10 эш көне эчендә карап тикшерә.

4. Бенефициар таләбе һәм Гарант тарафыннан Бенефициар таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту түбәндәге очракларда нигезсез дип таныла:

1) таләп Гарантиядә билгеләнгән срок узганнан соң гына Гарантка бирелсә;

2) таләп яисә аңа теркәлгән документлар Гарантия шартларына туры килмәсә;

3) Бенефициар Принципал яисә өченче затлар тәкъдим иткән Принципал йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне кабул итүдән баш тартса.

5. Бенефициар таләбе нигезле дип танылган очракта Гарант, Бенефициар таләбе нигезле дип танылган көннән соң 30 эш көне эчендә, Гарантия буенча йөкләмәне үти.

6. Гарантның бенефициар каршындагы Гарантиядә каралган йөкләмәсе бенефициар таләбе куелган вакытта үтәлми калган һәм гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләре суммасын түләү белән чикләнә, әмма бу гарантия бирелгән суммадан артмаска тиеш.

Гарант Принципалның штрафлар, комиссияләр, пенялар түләү турындагы йөкләмәләре үтәлешен гарантияләми.

7. Гарантның Гарантия буенча Бенефициар каршындагы йөкләмәләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) Гарант Гарантия белән билгеләнгән сумманы Бенефициарга түләгәндә;

2) Гарантиянең билгеләнгән бирелү срогы чыкканда;

3) Принципал яки өченче затлар тарафыннан Принципалның Гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләре тулы күләмдә үтәлгән очракта;

4) Бенефициар Гарантка кире кайтару юлы яки Гарантны аның йөкләмәләреннән азат итү турында язмача гаризасы белән Гарантия буенча үз хокукларыннан баш тарту нәтиҗәсендә;

5) Принципалның тәэмин итү өчен Гарантия бирелгән йөкләмәсе барлыкка килмәсә.

8. Гарантия Гарант тарафыннан түбәндәге очракларда кире алынырга мөмкин:

1) Кредит килешүенә Гарант белән килешенмәгән һәм җаваплылыкны арттыруга яки Гарант өчен башка тискәре нәтиҗәләргә китерә торган шартлар кертелгәндә, шул исәптән кредит һәм кредит буенча процент ставкасы күләме, Кредит килешүенең гамәлдә булу срогы үзгәргән очракта;

2) Кредит килешүен өзгәндә.

9. Принципалга Гарантия Гарантның Принципалга карата регресс таләбе хокукыннан башка бирелә.

10. Гарантия буенча Гарантка карата Бенефициарның таләп хокукы башка затка тапшырыла алмый.

11. Гарантия «____» ___________ 20___ елдан үз көченә керә һәм «____» _________ 20___ елга кадәр гамәлдә була.

Башкарма комитет
Җитәкчесе
М.У.